КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 декабрь г.Казань № 1205

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы программасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 3 декабрь, 825 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы чаралары программасы турында нигезләмәне раслау хакында»;

преамбулада «яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын» сүзләрен «өстәмә һөнәри белемгә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «программасы турында нигезләмәне» сүзләрен «чаралар программасы турында нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы программасы турында нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы чаралары программасы турында нигезләмә»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Нигезләмә, дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча чараларның шәхси планын исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри үсеш буенча чараларда катнашуын оештыруга нигезләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органының чаралар программасын (алга таба – Дәүләт органы чаралары программасы) формалаштыру тәртибен билгели.»;

2 пунктта «дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүне, аларның квалификациясен күтәрүне һәм стажировкасын үткәрүне» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри үсеш буенча чараларда катнашуы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «яңадан һөнәри әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм стажировкасын үткәрүгә» сүзләрен «һөнәри үсеш буенча чаралар» сүзләренә, «программаларын» сүзен «чаралар программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

беренче абзацта «программасы» сүзен «Чаралар программасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары категорияләре һәм төркемнәре, һөнәри үсеш чаралары юнәлешләре, төрләре, формалары һәм һөнәри үсеш буенча чараларны тормышка ашыру дәвамлылыгы буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча чараларга еллык ихтыяҗ фаразын;»;

өченче абзацта «программасын» сүзен «Чаралар программасы» сүзләренә, «өстәмә һөнәр белеме бирү буенча» сүзләрен «һөнәри үсеш буенча» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «программасы» сүзен «Чаралар программасы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты белән» сүзләрен « Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты белән» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләт органының тиешле Чаралар программасы әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән үрнәк форма буенча рәсмиләштерелә.»;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы программасы турындагы вакытлыча нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы программасы турындагы вакытлыча нигезләмәгә 2 нче, 3 нче кушымталар үз көчен югалткан дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә дәүләт заказын формалаштыру тәртибе турында» 2010 ел, 25 июнь, 519 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 1 июль, 528 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1028 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча чараларга дәүләт заказын формалаштыру тәртибе турында»;

преамбулада «яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә» сүзләрен «һөнәри үсеш буенча чараларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта «яңадан һөнәри әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм стажировкасын үткәрү» сүзләрен «һөнәри үсеш буенча чараларны тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «яңадан һөнәри әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә» сүзләрен « һөнәри үсеш буенча чараларны тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

3 пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм стажировкасын үткәрү буенча белем бирү хезмәтләре күрсәтү минималь кыйммәтенең икътисадый нормативларында:

исемен түбәндәге  редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча чараларны тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү минималь кыйммәтенең икътисадый нормативлары»;

таблицаның 1 юлындагы 3 графада «Белем бирү төрләре» сүзләрен «Һөнәри үсеш буенча чаралар төрләре» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә һәм аларның квалификациясен  күтәрүгә дәүләт контрактының үрнәк формасын яңа редакциядә бәян итәргә (кararга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы чаралары программасы турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 21 декабрь, 1205 нче карары редакциясендә)

Форма

Килештерелде
Татарстан Республикасы Президенты
каршындагы дәүләт хезмәте һәм
кадрлар департаменты җитәкчесе
____________________
«___» ____________20__ ел

Расланган
Дәүләт хакимияте органы җитәкчесе
____________________
«___» ____________20__ ел

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы чаралары программасы

| Дәүләт хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча чаралар төре | Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары | | Һөнәри үстерү буенча чарага юнәлдерелгән хезмәткәрләр саны | | | Аудит сәгатьләренең планлаштырылган саны | | Чараның планлаштырылган юнәлеше | | | | | | Һөнәри үсеш буенча чарага төп юнәлешләр | | | Һөнәри үсеш буенча чарада катнашкан хезмәткәрләр саны (гамәлдә) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | категория | төркем | 20__ ел | 20__ ел | 20__ ел | 18-72 | 73-144 | Оештыру-идарә итү | финан-с | мәгълүмати-аналитик | документларга кереш | хокукый | бүтән | кабат кабул ителгәннәр | аттес-тация буенча | планлы тәртиптә | 20__ ел | 20__ ел | 20__ ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| | җитәкчеләр | югары | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | төп | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | әйдәүче | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | ярдәмчеләр | төп | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | әйдәүче | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | белгечләры | әйдәүче | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | тәэмин итүче белгечләр | әйдәүче | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | өлкән | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | кече | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

_______________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2010 ел, 25 июнь, 519 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 декабрь, 1205 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә __________нчы (нче) дәүләт контракты

Казан шәһәре 2010 ел «__» ________

Татарстан Республикасы исеменнән ____________________________________________________
(вәкаләтләрне таныклый торган хокук актының исеме һәм реквизитлары)
нигезендә эш итүче _______________________________________________________________
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
йөзендә
_______________________________________________________________
________________________________
(дәүләт органы (органнары) исеме (исемнәре)
(алга таба – Заказчы) бер яктан, һәм ____________________________________________________
(вәкаләтләрне таныклый торган документ исеме һәм реквизитлары)
нигезендә эш итүче ________________________________________________________
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
йөзендә ___________________________________________________________________
(белем бирү учреждениесе исеме)
(алга таба – Башкаручы) икенче яктан (алга таба – Яклар), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының __________________________________________________
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты реквизатлары)
белән расланган 20 ___ елга Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә дәүләт заказы нигезендә
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(түбәндәгеләр нәтиҗәләре буенча: ачык конкурс (конкурс комиссиясе
_______________________________________________________________________________
утырышы беркетмәсе күрсәтелә һәм теркәлә)
_______________________________________________________________________________
котировкалар сорашу юлы белән заказлар урнаштыру (котировкалар комиссиясе утырышы беркетмәсе
_______________________________________________________________________________
күрсәтелә һәм теркәлә) бердәнбер башкаручыда урнаштыру – кирәклесен күрсәтергә)
түбәндәгеләр турында бу дәүләт контрактын төзеде.

## I. Дәүләт контракты предметы

1. Белем бирү программасының (программаларының) уку-укыту планы (планнары) нигезендә, Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтеннән
_______________________________________________________________________________

(эштән аерылып, өлешчә аерылып, аерылмыйча – кирәклесен күрсәтергә)

______________________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы дәүләт органы (органнары) исеме)

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре)________________________________________________________________

(яңадан һөнәри әзерләү, квалификация күтәрү – кирәклесен күрсәтергә)

______________________________________________________________________________

(белем бирү программасы (программалары) (алга таба – белем бирү программасы (программалары)

буенча өстәмә белем бирүче белем бирү программасы (программалары) буенча хезмәтләр күрсәтү бурычларын Заказчы йөкли, ә Башкаручы үз өстенә ала.

Белем бирү программасы (программалары) буенча белем алучылар саны ____________ (______________________) кеше.

(саннарда) (сүзләр белән язып)

Белем алу урыны ______________________________________________________.

II. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2. Заказчы түбәндәгеләрне башкарырга йөкләмә ала:

а) граждан хезмәткәрләре били торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын исәпкә алып, укучылар төркемнәре составын формалаштырырга;

б) граждан хезмәткәрләрен белем алуга һәм йомгаклау аттестациясен үтүгә үз вакытында җибәрергә;

в) бу дәүләт контрактының V бүлеге нигезендә Башкаручы күрсәткән белем бирү хезмәтләрен кабул итәргә һәм, аларның күләменә, сыйфатына һәм аларны күрсәтү вакытларын үтәүгә карата дәгъвалар булмаса, белем бирү хезмәтләрен тапшыру–кабул итү актына кул куярга;

г) Башкаручы күрсәткән хезмәтләргә Яклар белем бирү хезмәтләре күрсәтүне тапшыру–кабул итү актларына кул куйганнан соң 10 көн эчендә түләргә;

д) укуларын тәмамлаганнан соң граждан хезмәткәрләренә алынган белемнәрдән һәм күнекмәләрдән файдалану өчен шартлар тудырырга.

3. Заказчы түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Башкаручы белем бирүнең уку-укыту планы нигезендә күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын тикшерүдә тотарга (шул исәптән Башкаручы төзи торган тиешле дәүләт аттестация комиссиясе эшендә катнашу юлы белән);

б) бу дәүләт контрактын үтәгәндә, Башкаручы белән килештереп, бу дәүләт контракты белән күздә тотылган хезмәт күрсәтүләр күләмен, бу дәүләт контракты белән билгеләнгән бәяне тиешенчә үзгәртеп, 10 процентка кадәр үзгәртергә;

в) Башкаручыга, күрсәтелә торган хезмәтләрне тикшерүдә тоту максатыннан чыгып, бу дәүләт контрактын үтәүнең барышы турында сораулар җибәрергә.

4. Башкаручы түбәндәгеләрне үз өстенә ала:

а) уку-укыту процессын оештыруны һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең белем бирү программасын үзләштерүе өчен кирәкле шартлар тудыруны;

б) белем алу өчен кабул ителә торган граждан хезмәткәрләрен уку-укыту-методик материаллар һәм уку-укыту процессы өчен кирәкле башка материаллар белән тәэмин итүне[2];

в) белем алучылар төркемнәрен кабул итүне оештыруны һәм Заказчы акчасы исәбеннән читтән килгән тыңлаучыларга белем алуның барлык чорына яшәү өчен урын бирүне[1];

г) _____________________________________________________________________

(дәүләт органы (органнары) исеме)

граждан хезмәткәрләренең ______________________________________________ буенча

(яңадан кабат әзерләү, квалификация күтәрү – кирәген күрсәтергә)

---

[1] Белем бирү хезмәтләре күрсәтү күләмен үзгәртү мөмкинлеге конкурс документлары белән күздә тотылган очракта һәм бары тик дәүләт контрактына тиешле үзгәрешләр кертелгәндә генә.

белем бирү программасын граждан хезмәткәрләрен яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә карата дәүләт таләпләре һәм белем бирү планы нигезендә үзләштерүен тәэмин итәргә, шул исәптән______________________________

_____________________________________________________________________________________,

(дәүләт органы исеме)

дәүләт граждан хезмәткәрләре тиешле тематика буенча белем алырга тиешле шәхси биремне (булган очракта) үтәү өчен шартлар тәэмин итәргә;

д) дәүләт аттестация комиссиясе төзергә, граждан хезмәткәрләрен ___________

_____________________________________________________________________________________

(яңадан һөнәри әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү – кирәген күрсәтергә)

йомгаклары буенча йомгаклау аттестациясе үткәрергә һәм белем бирү курсын уңышлы тәмамлаганнарга______________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

(үтелгән белем бирү программасы нигезендә дәүләт үрнәгендәге документ)

бирергә;

е) укып бетергәннән соң бер ел эчендә Заказчы инициативасы буенча үткәрелә торган белем алган дәүләт хезмәткәре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге буенча мониторингта үз вәкиленең катнашуын тәэмин итүне.

5. Башкаручы түбәндәгеләргә хокуклы:

а) белем бирү программасы белән күздә тотылган дисциплиналарны укыту өчен шартнамә нигезендә дәүләт органнары җитәкчеләре һәм белгечләре арасыннан югары квалификацияле белгечләр, шулай ук Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү учреждениеләре укытучыларын җәлеп итәргә[2];

б) белем алучы граждан хезмәткәрләрен белем бирү учреждениесе уставында күздә тотылган нигезләр буенча, шулай ук алар белем бирү учреждениесенең эчке эш тәртибе кагыйдәләрен тупас яки системалы рәвештә бозган очракта, шулай ук белем бирү программасы планы белән күздә тотылган контроль биремнәрне үтәмәгән очракта, учреждениедән җибәрергә, бу турыда хезмәткәрләре яңадан белем алырга һәм квалификацияләрен күтәрергә тиешле________________________

_____________________________________________________________________________________,

(дәүләт органы исеме)

3 көн эчендә хәбәр итеп.

## III. Хезмәт күрсәтүләр кыйммәте (контракт бәясе) һәм исәп-хисаплар ясау тәртибе

6. ________________________________________________________________________

(дәүләт органы исеме)

дәүләт хезмәткәрләренә белем бирү кыйммәте бу дәүләт контракты буенча ________________________ (__________________________________________________________

(сумма саннарда)

_____________________________________________) сум тәшкил итә.

(сумманы сүзләр белән язып)

Заказчы бу дәүләт контрактын төзегәннән соң Башкаручыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бу дәүләт контракты буенча белем бирү хезмәтләре күрсәтү кыйммәтенең _______ проценты күләмендә ____________________

(_____________________________________________________

(сумманы сүзләр белән язып)

____________________________________________________) сум күләмендә аванс түли[3].

---

[2] Белем алуның барлык чорына читтән килгән тыңлаучыларны яшәү урыны белән тәэмин итү, конкурс документлары яки кодировкалар сорату турындагы хәбәрнамә йә бердәнбер башкаручы белән төзелгән килешүдә күздә тотылган очракта

[3] Аванс күләме конкурс документлары яки котировкаларны сорату турындагы хәбәрнамә нигезендә билгеләнә.

(сумманы сүзләр белән язып)

7. Бу дәүләт контракты буенча түләүләр 20 ___ елга граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүгә күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла, аннан Россия Федерациясе Салым кодексының 149 статьясындагы 2 нче пунктның 14 нче пунктчасы нигезендә өстәмә кыйммәткә салым алынмый.

8. Башкаручы күрсәткән хезмәтләр өчен арадаш һәм соңгы исәп-хисаплар Яклар аларны күрсәтү факты буенча төзи торган тиешле хезмәт күрсәтүләрне тапшыру-кабул итү акты нигезендә бу дәүләт контракты буенча белем бирү хезмәтләрен (аларның бер өлешен) күрсәтеп бетергәннән соң Заказчы белән Башкаручы арасында ясала.

Соңгы исәп-хисап фактта күрсәтелгән хезмәтләр буенча, тиешле хезмәт күрсәтүләрне тапшыру-кабул итү буенча арадаш актларны исәпкә алып, бирелгән аванс түләүләре суммасын чигереп гамәлгә ашырыла. Соңгы исәп-хисап Яклар хезмәт күрсәтүләрне тапшыру-кабул итү актына кул куйган көннән соң 10 көн эчендә ясала.

9. Граждан хезмәткәре бу дәүләт контрактының 5 нче пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән сәбәпләр буенча укудан җибәрелгән очракта, Башкаручы күрсәткән хезмәтләр өчен фактта күрсәтелгән хезмәтләргә тигез күләмдә түләнә.

## IV. Белем бирү шартларын үзгәртү, вакытларын күчерү, дәүләт контрактын өзү

10. Бу дәүләт контрактына кертелә торган үзгәрешләр язма рәвештә рәсмиләштерелә, Яклар тарафыннан имзалана һәм бу дәүләт контрактының аерылгысыз өлеше булып тора.

11. Белем алу өчен җибәрелә торган граждан хезмәткәрләре санын һәм шәхси составын, шулай ук граждан хезмәткәрләрен укыту урынын һәм вакытларын үзгәртүгә бәйле мәсьәләләр Яклар тарафыннан оператив тәртиптә хәл ителергә мөмкин, бу вакытта белем ала башлаганга 2 атна кала мондый үзгәрешләрнең зарурлыгы турында Башкаручыга хәбәр итү шарты үтәлергә тиеш.

12. Бу дәүләт контрактын өзү Яклар килешүе яки суд карары буенча Россия Федерациясенең граждан законнары белән күздә тотылган нигезләр буенча рөхсәт ителә.

Белем бирү урынын һәм вакытларын үзгәртү техник биремдә һәм уку-укыту планында күрсәтелгән белем бирү шартларын һәм сыйфатын начарайтырга тиеш түгел.

## V. Башкарылган эшләрне һәм күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибе

13. Башкаручы белем бирү төгәлләнгән көннән алып 10 көн эчендә тапшыру-кабул итү актын кул куйдыру өчен Заказчыга кертә, анда фактта күрсәтелгән хезмәтләр турында, шулай ук бу дәүләт контрактын үтәүгә бәйле рәвештә үзе тоткан чыгымнар хакындагы тулы мәгълүматны күрсәтә.

Тапшыру–кабул итү актын алган көннән башлап 10 көн эчендә Заказчы кул куелган тапшыру-кабул итү актын Башкаручыга кертергә тиеш.

Күрсәтелгән белем бирү хезмәтләре белем бирү программасының уку-укыту планына яки бу дәүләт контракты шартларына туры килмәү ачыкланган очракта, Заказчы тапшыру-кабул итү актын алган көннән 5 көн эчендә Башкаручыга тапшыру-кабул итү актына кул куюдан баш тартуы турында нигезләнгән хәбәр җибәрә.

Башкаручыдан аңлатмалар алганнан соң, Заказчы күрсәтелгән хезмәтләрне бәяләү өчен Россия Федерациясенең заказлар урнаштыру турындагы законнары нигезендә бәйсез экспертлар җәлеп итәргә хокуклы.

## VI. Якларның җаваплылыгы

14. Башкаручы дәүләт хезмәткәре алган белемнәрнең һәм күнекмәләрнең сыйфаты өчен законнар нигезендә җавап бирә.

Заказчы дәүләт хезмәткәренә уку тәмамланганнан соң алган белемнәрен һәм күнекмәләрен куллану таләп ителә торган вазыйфаи функцияләр үтәү мөмкинлеген бирү өчен җаваплы була.

15. Яклар бу дәүләт контракты йөкләмәләрен җиңеп булмаслык көчкә ия булган хәлләр аркасында үти алмаса, аларны тулысынча яки өлешчә үтәүдән азат ителә.

16. Җиңеп булмаслык көчкә ия булган хәлләр килеп чыгу аркасында бу дәүләт контракты йөкләмәләрен үти алмый торган Як алар барлыкка килгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча раслый торган документ белән бергә икенче Якка мондый хәлләр килеп чыгу турында язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш. Күрсәтелгән хәлләр үткән очракта, Як 5 көн эчендә икенче Якка бу турыда язма рәвештә хәбәр итәргә һәм кыска вакытларда бу дәүләт контракты буенча үз йөкләмәләрен үтәп булмый торган киртәләрне бетерү өчен мөмкин булган барлык нигезле чараларны күрергә тиеш.

Җиңеп булмаслык көчкә ия булган хәлләр килеп чыгу аркасында бу дәүләт контракты буенча йөкләмәләрен үти алмау турында икенче Якка хәбәр итмәү яки үз вакытында хәбәр итмәү бу Як өчен әлеге хәлләрне сылтау итү хокукын югалтуга китерә.

17. Заказчы бу дәүләт контракты белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәүне кичектереп торган очракта, Башкаручы неустойка (штраф, пеня) түләүне таләп итәргә хокуклы. Неустойка (штраф, пеня) бу дәүләт контракты белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәүне кичектереп торган һәр көн өчен бу дәүләт контракты белән билгеләнгән йөкләмәләрне үтәү вакыты чыкканнан соң икенче көннән башлап исәпләнә. Мондый неустойка (штраф, пеня) күләме Россия Федерациясе Үзәк банкының неустойка (штраф, пеня) түләү көненә гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә билгеләнә Заказчы, әлеге йөкләмәләрне үтәүне кичектереп тору җиңеп булмаслык көчкә ия булган хәлләр барлыкка килү аркасында яки Башкаручы гаебе буенча килеп чыкканлыкны исбатлый алса, неустойка (штраф, пеня) түләүдән азат ителә.

18. Башкаручы бу дәүләт контракты белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәүне кичектереп торган очракта, Заказчы неустойка (штраф, пеня) түләүне таләп итәргә хокуклы. Неустойка (штраф, пеня) бу дәүләт контракты белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәүне кичектереп торган һәр көн өчен бу дәүләт контракты белән билгеләнгән йөкләмәләрне үтәү вакыты үткәннән соң икенче көннән башлап исәпләнә. Мондый неустойка (штраф, пеня) күләме Россия Федерациясе Үзәк банкының неустойка (штраф, пеня) түләү көненә гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә билгеләнә. Башкаручы әлеге йөкләмәләрне үтәүне кичектереп тору җиңел булмаслык көчкә ия булган хәлләр барлыкка килү аркасында яки Заказчы гаебе буенча килеп чыкканлыкны исбатлый алса, ул неустойка (штраф, пеня) түләүдән азат ителә.

19. Бу дәүләт контракты буенча барлык бәхәсләр һәм каршылыклы фикерләр Яклар арасында сөйләшүләр юлы белән хәл ителә. Яклар бер фикергә килә алмаган очракта, бәхәсләр суд тәртибендә каралырга тиеш.

## VII. Йомгаклау нигезләмәләре

20. Бу дәүләт контракты бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде. Бу дәүләт контракты аңа Яклар кул куйган көннән үз көченә керә.

21. Бу дәүләт контрактының гамәлдә булу вакыты – 20____ елның ______________ 20 _____ елның __________ кадәр.

22. Бу дәүләт контрактына теркәлгән барлык кушымталар аның аерылгысыз өлеше була.

23. Яклар урнашкан урын һәм аларның банк реквизитлары:

| Заказчы: | Башкаручы: |
|---|---|
| ______________________________ | ______________________________ |
| 20__ елның______________________ | 20__ елның______________________ |

№__________ от «__» ___________ 20__елдагы Дәүләт контрактына кушымта

Форма

**Спецификация**

| **Күрсәтелә торган хезмәт исеме** | **Күрсәтелә торган хезмәт тасвирламасы** |
|---|---|
| | |

Барлык сумма ________________ (________________________________________) сум 00 тиен.

Заказчы

________________/ ______________ /

(М.У.)

Үтәүче

________________ /________________ /